СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2019 п.г.т. Алексеевское № 212

**Алексеевск шәһәр җирлеге Территориясендә үзара салым кертү һәм җыелган средстволарны куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасы Референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы," Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 нче статьясы, Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2019 елның 1 октябрендәге 15 номерлы карары, Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының « Референдум үткәрү инициативасы турында " 2019 елның 1 октябрендәге 211 номерлы карары нигезендә Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карары» нигезендә

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар итте:**

1. 2019 елның 24 ноябренә Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

"Сез 2020 елда Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән ,һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү , һәм дә салымнан 1 нче төркем инвалидларны, көндезге бүлектә укучы студентларны, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә

чакырылган гражданнарны, 18 яшькә кадәрге ,тәрбияләрендә 3тән артык баласы булган күп балалы гаиләләрне азат итеп,алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә :

- поселок эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;
- балалар өчен уен мәйданчыклары сатып алу һәм урнаштыру;;
- урамнарны һәм ял зоналарын төзекләндерү һәм яшелләндерү;
- һәйкәлләр төзү һәм төзекләндерү;
- зиратларны карап тоту һәм төзекләндерү;
- сууткәргеч һәм канализация челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләүгә тотуга ризамы?

Әйе Юк».

3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**